КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 11 ноябрь г.Казань № 1012

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы мәгарифен һәм фәнен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2014 ел, 22 февраль, 110 нчы карары белән расланган «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы мәгарифен һәм фәнен үстерү» дәүләт программасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы мәгарифен һәм фәнен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2014 ел, 22 февраль, 110 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 30 декабрь, 1063 нче; 2015 ел, 8 май, 333 нче; 2015 ел, 17 июнь, 444 нче; 2015 ел, 30 ноябрь, 906 нчы; 2016 ел, 30 март, 181 нче; 2016 ел, 25 май, 349 нчы; 2016 ел, 13 сентябрь, 640 нчы; 2016 ел, 21 сентябрь, 670 нче; 2016 ел, 28 ноябрь, 877 нче; 2017 ел, 25 гыйнвар, 29 нчы; 2017 ел, 28 апрель, 254 нче; 2017 ел, 26 июнь, 430 нчы; 2017 ел, 12 август, 568 нче; 2017 ел, 6 октябрь, 766 нчы; 2017 ел, 11 декабрь, 967 нче; 2018 ел, 27 март, 176 нчы; 2018 ел, 10 май, 343 нче; 2018 ел, 29 август, 735 нче; 2018 ел, 20 декабрь, 1198 нче; 2019 ел, 16 гыйнвар, 12 нче; 2019 ел, 13 февраль, 102 нче; 2019 ел, 6 июнь, 474 нче; 2019 ел, 31 октябрь, 974 нче; 2019 ел, 30 декабрь, 1246 нчы; 2020 ел, 24 июль, 618 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «2014 – 2025

елларга Татарстан Республикасы мәгарифен һәм фәнен үстерү» дәүләт программасына (алга таба – Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Программа паспортының «Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Программаны финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Программаны финанслау күләмнәре | Программаның федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән бюджет ассигнованиеләре күләмнәре 466 998 670,81 мең сум тәшкил итәчәк, шул исәптән түбәндәге еллар буенча:<br>2014 ел – 30 831 624,92 мең сум (шул исәптән капитал салуларга – 3 276 380,3 мең сум);<br>2015 ел – 40 434 999,8 мең сум (шул исәптән капитал салуларга – 10 287 192,8 мең сум);<br>2016 ел – 42 370 549,4 мең сум (шул исәптән капитал салуларга – 12 319 020,9 мең сум);<br>2017 ел – 39 584 370,3 мең сум (шул исәптән капитал салуларга – 8 141 860,8 мең сум);<br>2018 ел – 65 440 908,71 мең сум (шул исәптән капитал салуларга – 15 892 374,91 мең сум);<br>2019 ел – 63 989 186,46 мең сум (шул исәптән капитал салуларга – 20 146 126,41 мең сум);<br>2020 ел – 61 789 729,44 мең сум (шул исәптән капитал салуларга – 15 140 215,1 мең сум);<br>2021 ел – 63 144 292,0 мең сум (шул исәптән капитал салуларга – 16 152 768,4 мең сум);<br>2022 ел – 59 281 602,9 мең сум (шул исәптән капитал салуларга – 12 113 387,0 мең сум);<br>2023 ел – 39 279,6 мең сум (шул исәптән капитал салуларга – 2 323,3 мең сум);<br>2024 ел – 92 127,28 мең сум.<br>2023 – 2025 елларга акча күләме фараз характерында була һәм тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законы белән билгеләнә»; |

3 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

Программаның федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән бюджет ассигнованиеләре күләмнәре 466 998 670,81 мең сум тәшкил итәчәк, шул исәптән түбәндәге еллар буенча:

2014 ел – 30 831 624,92 мең сум (шул исәптән капитал салуларга – 3 276 380,3 мең сум);

2015 ел – 40 434 999,8 мең сум (шул исәптән капитал салуларга – 10 287 192,8 мең сум);

2016 ел – 42 370 549,4 мең сум (шул исәптән капитал салуларга – 12 319 020,9 мең сум);

2017 ел – 39 584 370,3 мең сум (шул исәптән капитал салуларга – 8 141 860,8 мең сум);

2018 ел – 65 440 908,71 мең сум (шул исәптән капитал салуларга – 15 892 374,91 мең сум);

2019 ел – 63 989 186,46 мең сум (шул исәптән капитал салуларга – 20 146 126,41 мең сум);

2020 ел – 61 789 729,44 мең сум (шул исәптән капитал салуларга – 15 140 215,1 мең сум);

2021 ел – 63 144 292,0 мең сум (шул исәптән капитал салуларга – 16 152 768,4 мең сум);

2022 ел – 59 281 602,9 мең сум (шул исәптән капитал салуларга – 12 113 387,0 мең сум);

2023 ел – 39 279,6 мең сум (шул исәптән капитал салуларга – 2 323,3 мең сум);

2024 ел – 92 127,28 мең сум.

2023 – 2025 елларга акча күләме фараз характерында була һәм тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законы белән билгеләнә.»;

2 нче кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

«2014 – 2025 елларга гомуми белем бирүне (инклюзив белем бирүне кертеп) үстерү һәм әлеге өлкә хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрү» ярдәмче программасында:

ярдәмче программа паспортында:

«Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Ярдәмче программаны финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Ярдәмче программаны финанслау күләмнәре | Ярдәмче программа чараларын федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслау күләмнәре 208 124 448,96 мең сум тәшкил итәчәк, шул исәптән түбәндәге еллар буенча:<br>2014 ел – 17 205 591,64 мең сум;<br>2015 ел – 18 902 517,8 мең сум;<br>2016 ел – 18 161 160,9 мең сум;<br>2017 ел – 18 684 936,6 мең сум;<br>2018 ел – 20 796 481,8 мең сум;<br>2019 ел – 21 922 502,2 мең сум;<br>2020 ел – 30 383 867,24 мең сум;<br>2021 ел – 30 914 585,9 мең сум;<br>2022 ел – 31 023 721,3 мең сум;<br>2023 ел – 36 956,3 мең сум;<br>2024 ел – 92 127,28 мең сум. |

| | |
|---|---|
| | 2023 – 2025 елларга акча күләме фараз характерында була һәм тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законы белән билгеләнә»; |

«Ярдәмче программа максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (Ярдәмче программа нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары)» юлына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«дәүләт һәм муниципаль белем бирү оешмаларында башлангыч гомуми белем алучы укучыларның гомуми санына карата дәүләт һәм муниципаль белем бирү оешмаларында башлангыч гомуми белем алучы, түләүсез кайнар ризык белән тукланучы укучылар өлешен 100 процентка кадәр арттыру»;

1 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Гомуми белем бирү өлкәсенә тасвирнамә,
төп проблемалар тасвирламасы һәм үсеш фаразы

Татарстан Республикасында 2019/2020 уку елында 1 402 гомуми белем бирү оешмасы, шул исәптән 1 318 гомуми белем бирү мәктәбе һәм интернат мәктәп, сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен 53 мәктәп һәм интернат мәктәп, 2 шифаханә интернат мәктәп, девиант тәртипле балалар өчен 1 мәктәп, 10 кичке гомуми белем бирү мәктәбе, 16 дәүләткә карамаган мәктәп, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы ведомствосы буйсынуындагы 2 мәктәп (2018/2019 уку елында – 1 402 оешма) эшли. Аларда 433 599 бала (2018/2019 уку елында – 416 890 кеше) укый, 36 229 педагогик хезмәткәр, шул исәптән 31 926 укытучы эшли.

2019/2020 уку елында көндезге гомуми белем бирү оешмалары структурасында (кичке, шәхси мәктәпләр һәм Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы ведомствосы буйсынуында булмаган мәктәпләрне исәпкә алмыйча) башлангыч мәктәпләр өлеше 7,4 процент (102 мәктәп) тәшкил итә, аларда укучыларның гомуми саныннан 1,1 процент (4 662 кеше) белем ала. Башлангыч мәктәпләрнең гомуми саныннан 88,2 проценты (90 мәктәп) авыл җирлегенә туры килә.

Төп мәктәпләрнең чагыштырма авырлыгы барлык мәктәпләрнең гомуми саныннан 25,4 процент (349 мәктәп) тәшкил итә, аларда укучыларның гомуми саныннан 3,8 процент (16 727 кеше) белем ала.

Урта мәктәпләр өлеше көндезге гомуми белем бирү оешмаларының гомуми саныннан 63,1 процент (867 мәктәп) тәшкил итә, шуларның 49 проценты (425 мәктәп) авыл мәктәпләренә туры килә. Республиканың урта мәктәпләрендә укучыларның гомуми саныннан 93 процент (399 497 кеше) белем ала, шулардан шәһәр җирлегендә – шәһәр җирлегендәге мәктәп укучыларының гомуми саныннан 96,5 процент (338 917 кеше), авыл җирлегендә – авыл җирлегендәге мәктәп укучыларының гомуми саныннан 77,5 процент (60 580 кеше) белем ала.

Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен махсус (коррекцион) гомуми белем бирү оешмалары, девиант тәртипле балалар өчен оешмалар, шифаханә гомуми белем бирү оешмалары өлеше 4,0 процент (56 мәктәп)

тәшкил итә, аларда укучыларның гомуми санынннан 1,8 процент бала (8 017 кеше) белем ала.

Дәүләт тарафыннан белем бирү чыгымнарын субсидияләү рәвешендә күрсәтелә торган ярдәм нәтиҗәсендә башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы шәхси гомуми белем бирү оешмалары челтәре үсә. 2019/2020 уку елында республикада 16 шәхси мәктәп эшләде, аларда 2 271 мәктәп укучысы белем алды.

Елдан-ел бердәм дәүләт имтиханы (алга таба – БДИ) ата-аналар һәм чыгарылыш сыйныф укучылары ягыннан да, педагогик берлек ягыннан да күбрәк ышаныч яулый. Бу шул исәптән имтихан процедурасының объективлыгы өстеннән контроль көчәю фонында да бара.

2018 елдан Татарстан Республикасының барлык имтиханнар үткәрү пунктларында имтихан үткәрү өчен «Аудиториядә имтихан материалларының тулы комплектларын чыгару» һәм «Имтиханнар үткәрү пунктларында сканерлау» технологиясе кулланыла.

БДИ үткәрү чорында Татарстан Республикасында гомуми белем бирү мәктәпләре базасында, өйдә һәм медицина учреждениеләре базасында 83тән күбрәк имтиханнар үткәрү пункты эшли. Мәктәпләр базасында барлык имтиханнар үткәрү пунктлары стационар металл рамкалар һәм онлайн-режимда эшли торган видеокүзәтү системасы белән җиһазландырылган. Имтихан материалларын имтиханнар үткәрү пунктларына алып килү өчен инкассаторлар хезмәтләре кулланыла. Төбәк мәгълүмат эшкәртү үзәге базасында «Бердәм дәүләт имтиханын кара» порталында имтиханнар үткәрү барышын карау өчен ситуацион үзәк төзелә.

2020 елда Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларының 11 сыйныф чыгарылыш укучыларының дәүләт йомгаклау аттестациясе БДИ формасында 15 гомуми белем бирү предметы буенча үткәрелде. Бердәм дәүләт имтиханында 16 284 (2017 елда – 15 337, 2018 елда – 16 376, 2019 елда – 16 488) чыгарылыш сыйныф укучысы катнашты. Алдагы еллардагы кебек үк җәмгыять белеме (6 276), физика (3 873), биология (3 152), химия (2 593) кебек фәннәргә сорау зур.

Урта гомуми белем бирүнең мәгариф программалары буенча дәүләт йомгаклау аттестациясен үткәрү нәтиҗәлелегенең иң мөһим күрсәткечләреннән берсе – ул аттестат алган Татарстан Республикасының унберенче сыйныф укучылары өлеше. Шулай итеп, 2019/2020 уку елында чыгарылыш укучыларның 99,99 проценты аттестат алды, 0,01 проценты (2 укучы) аттестат алмады. Үткән уку елында чыгарылыш укучыларның 0,03 проценты (14 кеше) аттестат алмады.

Төп мәсьәләләр:

PISA буенча Татарстан Республикасы укучыларының гомуми белем бирү сыйфатын халыкара тикшерүдә катнашу нәтиҗәләре материалларын анализлау 15 яшьлек мәктәп укучыларының табигый-фәнни, математика һәм уку грамоталыгы җитәрлек дәрәҗәдә булмавы ачыкланды.

Үсеш фаразы:

1. Татарстан Республикасы укучыларының функциональ грамоталыгын камилләштерү нигезендә гомуми белем бирү сыйфатын яхшырту.

2. Белем бирү сыйфаты белән идарә итү механизмнарын камилләштерү (түбән нәтиҗәле мәктәпләр һәм имин булмаган социаль шартларда эшләүче мәктәпләр

белән эшләү аша; белем бирү сыйфатын бәяләү процедуралары объективлыгын арттыру; гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләренең нәтиҗәлелеген мониторинглау системасын кертү).

3. Педагогик белем бирү һәм педагогларның һөнәри үсеше системасын модернизацияләү.»;

2 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 33 пункт өстәргә:

«33. Татарстан Республикасының дәүләт белем бирү оешмаларында (муниципаль белем бирү оешмаларында) башлангыч гомуми белем алучы укучыларның түләүсез кайнар ризык белән туклануын оештыру чаралары

Россия Федерациясе Президентының Россия Федерациясе Федераль Собраниесенә 2020 елның 15 гыйнварындагы Юлламасы нигезендә 2020 елның 1 сентябреннән башлангыч гомуми белем бирүнең мәгариф программаларын үзләштерүче укучылар өчен түләүсез сәламәт кайнар ризык белән туклануны оештыруга этаплап күчү гамәлгә ашырылачак.

Россия Федерациясе субъектларының әлеге максатларга чыгым йөкләмәләрен финанслашу өчен Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субсидияләр бирү һәм бүлү кагыйдәләре Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 26 декабрендәге 1642 номерлы карары белән расланган «Мәгарифне үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасына 29 нчы кушымтада билгеләнгән.

2020 елның 1 сентябреннән Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан һәм башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча белем бирүне гамәлгә ашыручы 1 346 дәүләт һәм муниципаль мәгариф оешмасында 1 – 4 сыйныфларның 209 235 укучысы өчен түләүсез кайнар ризык белән туклануны оештыру планлаштырыла.»;

3 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Ярдәмче программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

Ярдәмче программа чараларын федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслау күләме 208 124 448,96 мең сум тәшкил итәчәк, шул исәптән түбәндәге еллар буенча:

2014 ел – 17 205 591,64 мең сум;
2015 ел – 18 902 517,8 мең сум;
2016 ел – 18 161 160,9 мең сум;
2017 ел – 18 684 936,6 мең сум;
2018 ел – 20 796 481,8 мең сум;
2019 ел – 21 922 502,2 мең сум;
2020 ел – 30 383 867,24 мең сум;
2021 ел – 30 914 585,9 мең сум;
2022 ел – 31 023 721,3 мең сум;
2023 ел – 36 956,3 мең сум;
2024 ел – 92 127,28 мең сум.

2023 – 2025 елларга акча күләме фараз характерында була һәм тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законы белән билгеләнә.»;

5 бүлекнең таблицасына түбәндәге эчтәлекле 55 пункт өстәргә:

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «55. | Дәүләт һәм муниципаль белем бирү оешмаларында башлангыч гомуми белем алучы укучыларның гомуми санына карата дәүләт һәм муниципаль белем бирү оешмаларында башлангыч гомуми белем алучы, түләүсез кайнар ризык белән тукланучы укучылар өлеше, процент | - | - | - | - | - | - | - | 100 | 100 | 100»; | | |

1 нче кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

«2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы мәгарифен һәм фәнен үстерү» дәүләт программасы кысаларында социаль һәм инженерлык инфраструктурасын үстерү» ярдәмче программасында:

ярдәмче программа паспортында:

«Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Ярдәмче программаны финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Ярдәмче программаны финанслау күләмнәре | Ярдәмче программа чараларын федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслау күләмнәре 113 471 649,92 мең сум тәшкил итәчәк, шул исәптән түбәндәге еллар буенча:<br>2014 ел – 3 276 380,3 мең сум;<br>2015 ел – 10 287 192,8 мең сум;<br>2016 ел – 12 319 020,9 мең сум;<br>2017 ел – 8 141 860,8 мең сум;<br>2018 ел – 15 892 374,91 мең сум;<br>2019 ел – 20 146 126,41 мең сум;<br>2020 ел – 15 140 215,1 мең сум;<br>2021 ел – 16 152 768,4 мең сум;<br>2022 ел – 12 113 387,0 мең сум;<br>2023 ел – 2 323,3 мең сум. |

| | |
|---|---|
| | 2023 – 2025 елларга акча күләме фараз характерында була һәм тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законы белән билгеләнә»; |

«Ярдәмче программаның максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (Ярдәмче программа нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары)» юлында:

егерме икенче абзацта «146» саннарын «126» саннарына алмаштырырга;

кырык бишенче абзацта «2022 елга 5 095 кешегә кадәр» сүзләрен «2 179 кешегә кадәр» сүзләренә алмаштырырга;

кырык алтынчы абзацта «2022 елга 18» сүзләрен «2024 елга 12» сүзләренә алмаштырырга;

кырык җиденче абзацта «30» саннарын «12» саннарына алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен матди-техник базасы яңартылачак гомуми белем бирү оешмалары санын 6 берәмлеккә кадәр арттыру;

физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен матди-техник базасы яңартылачак гомуми белем бирү оешмаларында укучылар санын 1 435 кешегә кадәр арттыру.»;

1 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Мәгариф өлкәсенә тасвирнамә,
төп проблемалар тасвирламасы һәм үсеш фаразы

Татарстан Республикасында 2019/2020 уку елында 1 402 гомуми белем бирү оешмасы эшли.

Соңгы өч елда укучыларның саны арту күзәтелә. Шулай итеп, 2016 елдан 2020 елга кадәр укучыларның саны 44,7 мең кешегә артты һәм 2020 елда 433,6 мең кеше (2016 елда – 388,9 мең кеше) тәшкил итте.

Икенче сменада шөгыльләнүче укучылар өлеше (федераль статистика күзәтүе формалары буенча), 2012/2013 уку елы белән чагыштырганда, 2019/2020 уку елында, укучыларның саны артуга бәйле рәвештә, 9,62 процентка кадәр артты.

2020 ел башына Татарстан Республикасында балалар төрле типтагы 1 023 белем бирү оешмасында мәктәпкәчә белем ала. Мәктәпкәчә белем бирүгә 224 меңнән артык бала җәлеп ителде.

2020 ел башына мәктәпкәчә белем алудан файдалану мөмкинлеге 3 яшьтән зуррак балалар өчен 97,5 процент, 0 яшьтән 3 яшькә кадәрге балалар өчен 67,5 процент тәшкил итә. Мәктәпкәчә белем бирү оешмаларына урнашу чиратында 0 яшьтән 3 яшькә кадәрге 15,8 мең бала теркәлгән.

Татарстан Республикасында мәктәпкәчә белем бирү оешмалары челтәрен үстерү, халык өчен мәктәпкәчә белем алудан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү мәсьәләсенә зур игътибар бирелә.

2013 елдан 2017 елга кадәр Татарстан Республикасында гомуми егәрлеге 23 620 урынга исәпләнгән 165 балалар бакчасы төзелде.

2018/2019 елларда Татарстан Республикасында «Демография» илкүләм проекты кысаларында 6 220 урын, шул исәптән 2 айдан 3 яшькә кадәрге балалар өчен 30 балалар бакчасы төзү һәм гамәлдәге балалар бакчаларында 4 төркемне үзгәртү юлы белән 3 200 урын булдырылды. Чыгымнарның кыйммәте 5,4 млрд. сумнан артык, шул исәптән федераль бюджеттан якынча 1 млрд.сум тәшкил итте.

2020/2021 елларда «Демография» илкүләм проектын гамәлгә ашыру кысаларында 49 яңа балалар бакчасы төзү һәм гамәлдәге балалар бакчаларында гомуми егәрлеге 10 меңнән артык урынга (шул исәптән 1,5 яшьтән алып 3 яшькә кадәрге балалар өчен 5 050 урынга) исәпләнгән 2 төркемне үзгәртү каралган. Чыгымнарның кыйммәте 10 млрд.сумнан артык, шул исәптән 2,73 млрд.сумы федераль бюджеттан булачак.

2020 елда 5 030 урынга (шул исәптән 1,5 яшьтән 3 яшькә кадәр – 2 525 урынга, 3 яшьтән 7 яшькә кадәр – 2 505 урынга) исәпләнгән 22 балалар бакчасы төзелә башлады .

Моннан тыш, Татарстан Республикасы җитәкчелегенең аерым йөкләмәләре кысаларында 345 урынга исәпләнгән 6 балалар бакчасы төзү гамәлгә ашырыла.

2022 елга 1,5 яшьтән 3 яшькә кадәрге балалар өчен мәктәпкәчә белем бирүдән 100 процент файдалану мөмкинлегенә ирешү планлаштырыла.

2012 елдан Татарстан Республикасының гомуми белем бирү оешмаларын капиталь ремонтлау программасы тормышка ашырыла.

Әлеге программа гамәлдә булган вакытта 20 млрд.сумнан артык гомуми суммага 819 гомуми белем бирү һәм 379 мәктәпкәчә белем бирү оешмаларына, шулай ук Татарстан Республикасында 115 мәктәпнең функциональ зоналарына ремонт ясалды.

2020 елда капиталь ремонт программасына 3,0 млн.сумнан артык гомуми суммага 171 белем бирү оешмасы (172 бина) (36 муниципаль мәктәп, 2 махсус (коррекцион) мәктәп һәм 1 кадетлар мәктәбе, 88 мәктәпкәчә белем бирү оешмасы (89 бина), 42 авыл муниципаль һәм 2 дәүләт гомуми белем бирү оешмасының функциональ зоналарын ремонтлау) кертелгән.

Татарстан Республикасында 2012 елдан «Уңайлы мохит» Россия Федерациясе дәүләт программасы гамәлгә ашырыла. Барлыгы аны гамәлгә ашыру чорында 557 млн.сумнан артык гомуми суммага 345 оешма (277 муниципаль мәктәп һәм 42 махсус (коррекцион) мәктәп, 20 мәктәпкәчә белем бирү оешмасы һәм 6 өстәмә белем бирү оешмасы) җайлаштырылган.

2020 елда югарыда күрсәтелгән программа кысаларында 16,5 млн.сумлык гомуми суммага (шулардан 9,6 млн.сумы – федераль бюджет, 6,9 млн.сумы – Татарстан Республикасы бюджеты) 12 белем бирү оешмасы (5 мәктәпкәчә белем бирү оешмасы, сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен 5 дәүләт гомуми белем бирү оешмасы һәм 2 балаларга өстәмә белем бирү оешмасы) бинасы җайлаштырыла.

Акча оешмаларның архитектур файдалану мөмкинлеген булдыруга һәм күрсәтелә торган хезмәтләрдән файдалану мөмкинлеген арттыру өчен җиһазлар сатып алуга җибәрелә.

2019/2020 уку елында 95 һөнәри белем бирү оешмасы эшли, аларда 70 меңнән артык кеше белем ала. Ел саен һөнәри белем бирү оешмаларына кабул итү якынча 22 мең кеше тәшкил итә.

2014 елдан Татарстан Республикасының база эш бирүчеләренең кадрлар ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен төзелә торган ресурс үзәкләре биналарын капиталь ремонтлау программасы гамәлгә ашырыла. 2014 елдан 2019 елга кадәрге чорда программа кысаларында 4,0 млрд.сумнан артык гомуми суммага һөнәри белем бирү оешмаларының 65 объекты ремонтланды.

2020 елда программага якынча 658 млн.сумга 17 белем бирү оешмасы бинасын ремонтлау кертелгән.

Шулай ук 2020 елда 190,49 млн.сумлык гомуми суммага урта һөнәри белем бирү оешмаларының өч тулай торагына ремонт ясау каралган.»;

2 бүлектә:

5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Авыл җирендә һәм кече шәһәрләрдә урнашкан
гомуми белем бирү оешмаларында физик культура һәм спорт белән
шөгыльләнү өчен («Мәгариф» илкүләм проектының «Һәр бала уңышы»
төбәк проектын гамәлгә ашыру кысаларында) шартлар тудыру

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, мәгариф белән идарә итү буенча муниципаль органнар эшчәнлеге үсеп килүче буынның сәламәтлеген ныгыту, балалар һәм яшүсмерләрне физик культура һәм спорт белән даими һәм массакүләм шөгыльләнүгә җәлеп итү өчен шартлар тудыруга юнәлдерелгән. Бүгенге көндә бу эшнең билгеле бер нәтиҗәләре бар.

Физкультура-сәламәтләндерү эшен оештыру өчен тиешле инфраструктураның булуы аерым әһәмияткә ия.

1 357 гомуми белем бирү оешмасында (шуларның 1 312е – юридик затлар һәм 45 филиал (гомуми белем бирү оешмаларының гомуми саныннан 81,65 процент)) 1 416 спорт залы эшли. Шулай ук гомуми белем бирү оешмаларының спорт-сәламәтләндерү инфраструктурасы түбәндәге объектлардан гыйбарәт: ачык яссы спорт корылмалары – 1 446, футбол кырлары – 517, баскетбол мәйданчыклары – 333, волейбол мәйданчыклары – 329, хәрәкәтчән уеннар өчен мәйданчыклар – 364, хоккей яисә боз мәйданчыклары – 292, спорт мәйданчыклары – 114, йөзү бассейннары – 49, тренажер мәйданчыклары – 78, чаңгы трассалары – 118.

Татарстан Республикасында гомуми белем бирү оешмаларында спорт залларының техник торышына ел саен мониторинг үткәрү гамәлгә ашырыла. Муниципаль берәмлекләрнең тәкъдимнәре буенча спорт залларында капиталь ремонт үткәрү таләп ителә торган гомуми белем бирү оешмалары исемлеге төзелә. Техник торышына һәм финанслау күләменә карап, спорт залларына капиталь ремонт ясалырга тиешле гомуми белем бирү оешмалары билгеләнә. Татарстан Респуб-

ликасы Министрлар Кабинетының боерыгы кабул ителгәннән соң, сатулар процедурасы өчен техник документлар эшләнә, алга таба генераль подрядчысы билгеләнә һәм, ремонт эшләрен башкару срокларын күрсәтеп, дәүләт контракты төзелә.

2014 – 2020 елларда авыл җирендә һәм кече шәһәрләрдә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларында физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен, шулай ук үсеп килүче буынның сәламәтлеген ныгыту, балалар һәм яшүсмерләрне физик культура һәм спорт белән даими һәм массакүләм шөгыльләнүгә җәлеп итү өчен шартлар тудыру максатларында гомуми белем бирү оешмаларының 123 спорт залына ремонт ясалды.

2021 – 2023 елларда авыл җирендә һәм кече шәһәрләрдә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларының 6 спорт залына (ел саен 2шәр) ремонт ясау планлаштырыла.

2020 ел башына республика гомуми белем бирү оешмалары базасында 544 мәктәп спорт клубы эшли.

Чараның бурычлары түбәндәгеләр була:

физик культура һәм спорт белән тулы кыйммәтле итеп шөгыльләнү мөмкинлеген тәэмин итү;

укучыларның хәрәкәт активлыгы дәрәҗәсен билгеләү;

гомуми белем бирү оешмаларының бер гомуми белем бирү оешмасы укучыларыннан төзелгән, спортның аеруча алга киткән һәм популяр җәйге олимпия төрләрендә иң яхшы нәтиҗәләргә ирешкән иң яхшы командаларын билгеләү;

массакүләм мәктәп спортын үстерү;

сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау;

укучыларны даими физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүгә җәлеп итү.

Шулай ук чараны гамәлгә ашыру кысаларында мәктәп спорт клубларын түбәндәге юнәлешләр буенча үстерү эше дәвам итәчәк:

клублар спорт, физкультура һәм сәламәтләндерү чараларын оештыру һәм үткәрү;

клубларны заманча спорт җиһазлары һәм җайланмалар белән җиһазландыру;

сәламәтлеге торышында тайпылышлар булган, сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән укучыларны физик тернәкләндерү эшен башкару, аларны массакүләм физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларында катнашуга җәлеп итү;

төрле спорт төрләре буенча командалар төзү һәм аларның төрле дәрәҗәдәге ярышларда катнашуын тәэмин итү;

гомуми белем бирү оешмаларында физик культура, спорт, сәламәт яшәү рәвешенең төп идеяләрен пропагандалау.

2015 – 2017 елларда «Авыл җирендә спорт залларын ремонтлау» программасы кысаларында авыл җирендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларын капиталь төзүне, реконструкцияләүне һәм капиталь ремонтлауны күздә тоткан чаралар исемлеге Ярдәмче программага 6 нчы кушымтада китерелгән.

2018 – 2022 елларда авыл җирендә һәм кече шәһәрләрдә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларын капиталь төзүне, реконструкцияләүне һәм капиталь

ремонтлауны күздә тоткан чаралар исемлеге Ярдәмче программага 11 нче кушымтада китерелгән.»;

6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Балаларга өстәмә белем бирү оешмаларында
капиталь ремонт үткәрү

2020/2021 уку елы башына Татарстан Республикасында 154 балаларга өстәмә белем бирү оешмасы эшли (шуларның 15,6 проценты авыл җирендә (24 оешма) урнашкан, 10,4 проценты (16 оешма) автоном белем бирү оешмасы булып тора, аларда 187 меңнән артык укучы шөгыльләнә.

104 өстәмә белем бирү оешмасының оператив идарә хокукында үзләренә караган 129 аерым урнашкан бинасы (яки биналарның бер өлеше) бар.

Ел саен балаларга өстәмә белем бирү биналарын ремонтлауга Татарстан Республикасы бюджетыннан һәм муниципаль бюджетлардан акча бүлеп бирелә.»;

3 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Ярдәмче программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

Ярдәмче программа чараларын федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслау күләмнәре 113 471 649,92 мең сум тәшкил итәчәк, шул исәптән түбәндәге еллар буенча:

2014 ел – 3 276 380,3 мең сум;
2015 ел – 10 287 192,8 мең сум;
2016 ел – 12 319 020,9 мең сум;
2017 ел – 8 141 860,8 мең сум;
2018 ел – 15 892 374,91 мең сум;
2019 ел – 20 146 126,41 мең сум;
2020 ел – 15 140 215,1 мең сум;
2021 ел – 16 152 768,4 мең сум;
2022 ел – 12 113 387,0 мең сум;
2023 ел – 2 323,3 мең сум.

2023 – 2025 елларга акча күләме фараз характерында була һәм тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законы белән билгеләнә.»;

5 бүлек таблицасында:

14 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «14. | Авыл җирендә урнашкан, спорт заллары ремонтланган гомуми белем бирү оешмалары саны, берәмлек | 30 | 38 | 22 | 14 | 6 | 6»; | | | | | | |

38 – 43 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «38. | Физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен | - | - | - | - | - | - | 6 | | | | | |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | шартлар тудырылачак гомуми белем бирү оешмалары саны, шулардан: | | | | | | | | | | | | |
| 38.1. | авыл җирендә урнашкан гомуми белем бирү оешмалары саны, берәмлек | - | - | - | - | - | - | 3 | | | | | |
| 38.2. | шәһәр тибындагы поселокларда урнашкан гомуми белем бирү оешмалары саны, берәмлек | - | - | - | - | - | - | 2 | | | | | |
| 38.3. | халык саны 50 мең кешедән артмаган (кече шәһәрләр) башка шәһәр җирлекләрендә урнашкан гомуми белем бирү оешмалары саны, берәмлек | - | - | - | - | - | - | 1 | | | | | |
| 39. | Физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудырылачак гомуми белем бирү оешмаларында укучылар саны, кеше, шулардан: | - | - | - | - | - | - | 2 179 | | | | | |
| 39.1. | авыл җирендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларында укучылар саны, кеше | - | - | - | - | - | - | 825 | | | | | |
| 39.2. | шәһәр тибындагы поселокларда урнашкан гомуми белем бирү оешмаларында укучылар саны, кеше | - | - | - | - | - | - | 720 | | | | | |
| 39.3. | халык саны 50 мең кешедән артмаган (кече шәһәрләр) башка шәһәр җирлекләрендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларында укучылар саны, кеше | - | - | - | - | - | - | 634 | | | | | |
| 40. | Гомуми белем бирү оешмаларында субсидия акчасы исәбеннән ремонтланган спорт заллары саны, берәмлек, шулардан: | - | - | - | - | - | - | 6 | 2 | 2 | 2 | | |
| 40.1. | авыл җирлегендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларында ремонтланган спорт заллары саны, берәмлек | - | - | - | - | - | - | 3 | 2 | 2 | 2 | | |
| 40.2. | шәһәр тибындагы поселокларда урнашкан гомуми белем бирү оешмаларында ремонтланган спорт заллары саны, берәмлек | - | - | - | - | - | - | 2 | - | - | - | | |
| 40.3. | халык саны 50 мең кешедән | - | - | - | - | - | - | 1 | - | - | - | | |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | артмаган (кече шәһәрләр) башка шәһәр җирлекләрендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларында ремонтланган спорт заллары саны, берәмлек | | | | | | | | | | | | |
| 40.4. | кече шәһәрләрдә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларында ремонтланган спорт заллары саны, берәмлек | - | - | - | - | - | - | - | 0 | 0 | 0 | | |
| 41. | Гомуми белем бирү оешмаларында физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен субсидия акчасы исәбеннән спорт заллары итеп эшләнгән аудиторияләр саны, берәмлек, шулардан: | - | - | - | - | - | - | 0 | 0 | 0 | 0 | | |
| 41.1. | авыл җирендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларында физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен спорт заллары итеп эшләнгән аудиторияләр саны, берәмлек | - | - | - | - | - | - | 0 | 0 | 0 | 0 | | |
| 41.2. | шәһәр тибындагы поселокларда урнашкан гомуми белем бирү оешмаларында физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен спорт заллары итеп эшләнгән аудиторияләр саны, берәмлек | - | - | - | - | - | - | 0 | - | - | - | | |
| 41.3. | халык саны 50 мең кешедән (кече шәһәрләр) артмаган башка шәһәр җирлекләрендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларында физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен спорт заллары итеп эшләнгән аудиторияләр саны, берәмлек | - | - | - | - | - | - | 0 | - | - | - | | |
| 41.4. | кече шәһәрләрдә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларында физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен спорт заллары итеп эшләнгән аудиторияләр саны, берәмлек | - | - | - | - | - | - | - | 0 | 0 | 0 | | |
| 42. | Гомуми белем бирү оешмаларында субсидия акчасы исәбеннән төзелгән | - | - | - | - | - | - | 6 | 2 | 2 | 2 | | |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | мәктәп спорт клублары саны, берәмлек, шулардан: | | | | | | | | | | | | |
| 42.1. | авыл җирендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларында оештырылган мәктәп спорт клублары саны, берәмлек | - | - | - | - | - | - | 3 | 2 | 2 | 2 | | |
| 42.2. | шәһәр тибындагы поселокларда урнашкан гомуми белем бирү оешмаларында оештырылган мәктәп спорт клублары саны, берәмлек | - | - | - | - | - | - | 2 | - | - | - | | |
| 42.3. | халык саны 50 мең кешедән артмаган (кече шәһәрләр) башка шәһәр җирлекләрендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларында оештырылган мәктәп спорт клублары саны, берәмлек | - | - | - | - | - | - | 1 | - | - | - | | |
| 42.4. | кече шәһәрләрдә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларында оештырылган мәктәп спорт клублары саны, берәмлек | - | - | - | - | - | - | - | 0 | 0 | 0 | | |
| 43. | Гомуми белем бирү оешмаларында субсидия акчасы исәбеннән спорт инвентарьлары белән тәэмин ителгән һәм җиһазландырылган ачык спорт яссы корылмалары саны, берәмлек, шулардан: | - | - | - | - | - | - | 0 | 0 | 0 | 0 | | |
| 43.1. | авыл җирендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларында спорт инвентаре белән тәэмин ителгән һәм җиһазландырылган ачык спорт яссы корылмалары саны, берәмлек | - | - | - | - | - | - | 0 | 0 | 0 | 0 | | |
| 43.2. | шәһәр тибындагы поселокларда урнашкан гомуми белем бирү оешмаларында спорт инвентаре белән тәэмин ителгән һәм җиһазландырылган ачык спорт яссы корылмалары саны, берәмлек | - | - | - | - | - | - | 0 | - | - | - | | |
| 43.3. | халык саны 50 мең кешедән артмаган (кече шәһәрләр) башка шәһәр җирлекләрендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларында | - | - | - | - | - | - | 0 | - | - | - | | |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | спорт инвентаре белән тәэмин ителгән һәм җиһазландырылган ачык спорт яссы корылмалары саны, берәмлек | | | | | | | | | | | | |
| 43.4. | кече шәһәрләрдә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларында спорт инвентаре белән тәэмин ителгән һәм җиһазландырылган ачык спорт яссы корылмалары саны, берәмлек | - | - | - | - | - | - | - | 0 | 0 | 0»; | | |

түбәндәге эчтәлекле 46 – 47 пунктлар өстәргә:

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «46. | физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен матди-техник базасы яңартылачак гомуми белем бирү оешмалары саны, берәмлек, шулардан: | - | - | - | - | - | - | - | 2 | 2 | 2 | | |
| 46.1. | авыл җирендә урнашкан гомуми белем бирү оешмалары саны, берәмлек | - | - | - | - | - | - | - | 2 | 2 | 2 | | |
| 46.2. | кече шәһәрләрдә урнашкан гомуми белем бирү оешмалары саны, берәмлек | - | - | - | - | - | - | - | 0 | 0 | 0 | | |
| 47. | Физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен матди-техник базасы яңартылачак гомуми белем бирү оешмаларында укучылар саны, кеше, шулардан: | - | - | - | - | - | - | - | 530 | 205 | 700 | | |
| 47.1. | авыл җирендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларында укучылар саны, кеше | - | - | - | - | - | - | - | 530 | 205 | 700 | | |
| 47.2. | кече шәһәрләрдә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларында укучылар саны, кеше | - | - | - | - | - | - | - | 0 | 0 | 0»; | | |

ярдәмче программага 1, 11 нче кушымталарны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин